| БАВЛИНСКИЙ ГОРОДСКОЙ СОВЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

23.10.2020 Баулы шәһәре № 12

Җир салымы турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 31нче бүлегенә ярашлы рәвештә, Баулы шәһәр Советы карар кылды:

1. Баулы муниципаль районының «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә түләү мәҗбүри булган җир салымын билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Салым ставкаларын түбәндәге күләмнәрдә билгеләргә:

1) авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләргә яисә торак пунктларда авыл хуҗалыгы куллану зоналары составындагы һәм авыл хуҗалыгы җитештерүе өчен файдаланыла торган җирләргә карата 0,3 %;

2) торак фонды һәм торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектлары биләгән җир кишәрлекләренә карата (торак фондына һәм торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектларына карамаган объектка туры килә торган җир кишәрлегенә хокуктагы өлештән тыш) яисә торак төзелеше өчен сатып алынган (эшкуарлык эшчәнлегендә кулланыла торган индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән тыш) - 0,3%;

3) эшмәкәрлек эшчәнлеге өчен кулланылмаган, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, бакчачылык яки яшелчәчелек алып бару өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләренә, шулай ук «Гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы Федераль законда каралган гомуми билгеләнештәге җир кишәрлекләренә карата карата - 0,3 %;

4) рекреацион һәм дәвалау-савыктыру билгеләнешендәге объектлар урнаштыру өчен билгеләнгән җир кишәрлекләренә карата - 0,12%;

5) Россия Федерациясе законнары нигезендә, әйләнеше чикләнгән, оборона, иминлек һәм таможня ихтыяҗларын тәэмин итү өчен бирелгән - җир кишәрлекләренә карата 0,3 %;

6) башка җир кишәрлекләренә карата 1,5 %.

3. Әлеге карарның 2нче пункты 6нчы пунктчасында каралган салым ставкасыннан ташлама билгеләргә:

- җирле бюджеттан финанслана торган автономияле, бюджет һәм казна учреждениеләренең җир кишәрлекләренә карата 13,3 процент күләмендә;

- шәхси ярдәмче кишәрлекләрдә үстерелгән үсемлек продукциясен сатучы гражданнар өчен сәүдә урыннары бирелә торган территорияләргә карата 6,67 процент күләмендә;

- дәвалау процессын тормышка ашыручы һәм дәвалау-профилактика оешмалары статусына ия шифаханә-курорт оешмалары урнашкан җир кишәрлекләренә карата 92 процент күләмендә.

4. Җир салымын түләүдән азат итәргә:

1) оешмалар - парклар, скверлар, урамнар, автомобиль юллары, машина юллары, мәйданнар, су объектлары, зиратлар биләгән гомуми файдаланудагы җир кишәрлекләренә карата;

2) шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, индивидуаль торак төзелеше, бакчачылык, яшелчәчелек һәм терлекчелек, шулай ук дача хуҗалыгы өчен бирелгән җир кишәрлекләренә карата Бөек Ватан сугышында катнашучыларны, шулай ук закончалык нигезендә, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның социаль гарантияләре һәм ташламаларыннан файдаланган гражданнарны;

3) «Чернобыль АЭСындагы һәлакәт аркасында радиация йогынтысына дучар булган гражданнарны социаль яклау турында» Россия Федерациясе Законы (24.04.2020 ред. ФЗ-147 номерлы) нигезендә социаль ярдәм алуга хокукы булган физик затлар;

4) I һәм II төркем инвалидлар, балачактан инвалидлар;

5) сугышчан хәрәкәтләр алып барылган Әфганстан Республикасында һәм башка илләрдә интернациональ бурычны үтәгән гражданнар;

6) Россия Федерациясе территориясендә хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан гражданнар;

7) 18 яшькә кадәрге дүрт һәм аннан күбрәк баласы булган, көндезге уку формасында белем алган 23 яшькә кадәрге баласы булган гражданнар. Салым ташламасы җир кишәрлеге рәсмиләштерелгән ата-ананың берсенә яисә, җир кишәрлеге өлешле милек булган очракта, ике ата-анага һәм балаларга бирелә. Хәбәрнамә салым түләүче тарафыннан салым органына салым ташламасы кулланыла торган салым чоры булган елның 1 ноябренә кадәр бирелә.

4нче пунктның 2-7 бүлекләрендә күрсәтелгән салым түләүчеләр категорияләренә салым ташламасы салым түләүче милкендәге һәм эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланылмый торган бер җир кишәрлегенә салым түләүче тарафыннан салым суммасы түләнергә тиешле күләмдә бирелә. Салым ташламасы салымның максималь күләме булган җир кишәрлегенә карата бирелә.

6. Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча 17нче районара инспекциясенә «Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасы турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 14 февралендәге 181 номерлы карары һәм ЕГИССО операторы билгеләгән тәртип һәм күләм нигезендә әлеге карар белән җир салымын түләүдән азат ителгән физик затларга карата социаль ярдәм чаралары турында мәгълүмат

бирүне тәкъдим итәргә.

5. «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Советының «Җир салымы турында» 2014 елның 11 декабрендәге 114 номерлы карарын (Баулы шәһәр Советының 2016 елның 28 сентябрендәге 43 номерлы, 2017 елның 15 июнендәге 53 номерлы, 2017 елның 25 октябрендәге 61 номерлы, 2017 елның 15 декабрендәге 67 номерлы, 2018 елның 31 августындагы 81 номерлы, 2018 елның 16 мартындагы 92 номерлы, 2019 елның 27 мартындагы 105 номерлы, 2019 елның 20 маендагы 108 номерлы, 2019 елның 16 октябрендәге 117 номерлы карарлары кертелгән үзгәрешләр белән) үз көчен югалткан дип танырга.

6. Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә, ләкин Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) рәсми басылып чыккан көненнән алып бер айдан да иртәрәк түгел.

Баулы шәһәре Мэры,
шәһәр Советы Рәисе Р.Х. Гатиятуллин